РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Верхнеуслонского муниципального района

422570, село Верхний Услон, ул. Чехова д. 18
тел.: (8843-79) 2-12-67, факс: (8843-79) 2-12-67
E-mail: Ispolkom.Verhniy-usl@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитеты

422570, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 18 нче йорт
тел.: (8843-79) 2-12-67, факс: (8843-79) 2-12-67
E-mail: Ispolkom.Verhniy-usl@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________________ №_________

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Югары Ослан муниципаль районы территориясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүне (исәпкә алуны) оештыру һәм гамәлгә ашыру турында»2006 елның 11 декабрендәге 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) дәүләт системасы эшчәнлеген тәэмин итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Президентының Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 10 апрелендәге ПУ-350 номерлы Указы нигезендә Югары Ослан муниципаль районы Уставына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Югары Ослан муниципаль районы территориясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүне (исәпкә алуны) оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 11 декабрендәге 28 номерлы карарының 2 нче кушымтасына (2011 елның 03.05.2011 № 512, 2013 елның 05 июлендәге 859, 2013 елның 22 ноябрендәге 1769 номерлы, 02.06.2014 елның 26 июнендәге 915 номерлы, 2012 елның 26 июнендәге 780 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүне (исәпкә алуны) гамәлгә ашырганда Югары Ослан муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе эшчәнлеген координацияләү буенча эш төркеме составыннан Камалетдинова Гөлия Фидаиловнаны чыгарырга;

Югары Ослан муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәгән (исәпкә алган) вакытта эшчәнлеген координацияләү буенча эш төркеме составына Сөләйманова Зөһрә Дилбәр кызын - Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигын кертергә.

2 нче кушымтаны кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкченең
№ _______ карарына
2 нче кушымта

Сайлаучыларны, референдум участокларын теркәүне (исәпкә алуны) тормышка ашырганда һәм теркәлгән сайлаучылар, референдумда катнашучылар санын билгеләгәндә Югары Ослан муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе эшчәнлеген координацияләү буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Тимиряев Виктор Сергеевич | Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Козина Светлана Анатольевна | Финанс-бюджет Палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Никитина Людмила Николаевна | Район Советы Аппараты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Минһаҗева Әлфия Корбангали кызы | Башкарма комитет эшләре идарәчесе |
| Кадыйрова Наталья Александровна | Башкарма комитетның ЗАГС бүлеге начальнигы |
| Сөләйманова Зөһрә Дилбәр кызы | Район Советының оештыру бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Шакиров Рөстәм Әзһәр улы | ТР Хәрби комиссариатының Югары Ослан районындагы бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Хохорин Олег Евгеньевич | Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Дәүләтшин Марсель Фәрит улы | Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Федераль миграция хезмәте идарәсенең Югары Ослан районында бүлек начальнигы (килешү буенча) |

Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче А.К. Минһаҗева